# СОВЕТ ЧОРЫ ТАТАР-ҮЗБӘК ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАРЫ

***Габдельхакова Г.М.***

# TATAR-UZBEK LITERARY RELATIONSHIPS OF THE SOVIET PERIOD

***Gabdulkhakova G.M.***

Татарстан Республикасының “Татар халкының милли үзенчәлеген саклау” (2013–2019) Дәүләт программасы кысаларында Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге хезмәткәрләре тарафыннан “Үзбәкстан татарлары” энциклопедия-белешмәлек басмага әзерләнә. Татар диаспорасы Үзбәкстан Республикасында иң зурлардан санала. Татар һәм үзбәк халкы гомер-гомергә аралашып, үзара дус-тату, бәйләнештә, бер-берсен үстерешеп яшәгән. Милләттәшләребез үзбәк халкының фән-гыйлем, мәдәният өлкәсендә тәрәккый итүенә үз хезмәтләре белән зур өлеш керткәннәр. Үзбәкстан Республиканың исемен данлаган, бигрәк тә мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә танылган милләттәшләребез белән без горурланабыз. Туган җирләреннән читтә – Үзбәкстанда шөһрәт казанган кайбер шәхесләребездән, мәсәлән, Үзбәкстанның халык язучысы, драматург Зиннәт Фәтхуллин; архитектура белгече Мидхәт Булатов; кинематографист-режиссер Заһид Сабитов; Үзбәкстанның һәм СССРның халык рәссамы Чыңгыз Әхмәрев; Үзбәкстанның һәм СССРның халык артисты, балерина Галия Измайлова; сәнгать белеме докторы, рәссам Рафаэль Такташ; язучы һәм журналист Җәүдәт Ильясов; киносценарист, театр һәм кино режиссеры Равил Батыров һәм тагын бик күпләр башка тугандаш төрки халыкларга да яхшы таныш. Тормышлары Үзбәкстан Республикасы белән бәйле атаклы милләттәшләребезгә 6 томлык Татар энциклопедиясе (рус варианты; Казан, 2002–2014) битләрендә лаеклы урын бирелде. “Үзбәкстан татарлары” энциклопедик басмасында мәкаләләр тулыландырыла, яңалары өстәлә, иллюстрацияләр белән баетыла. Анда шулай ук фән, хакимият, дәүләт, сәясәт, хуҗалык өлкәсендә казанышларга ирешкән шәхесләр дә керәчәк.

1917 елгы вакыйгалардан соң Урта Азия халыкларының мәдәни тормышында татарларның да кайнап яшәве Төркестанда туган телебездә берничә газета-журнал чыгып килү, китапханә һәм клублар, татар профессиональ театрлары эшләү, татар теле укытучы-

лары хәзерли торган институт булу белән дә бәйле. Ул елларда Үзбәкстанда язучылар берлеге каршында татар язучылары секциясе эшләгән. Әлеге мәкаләдә сүз әдәбият өлкәсендә үзенең иҗаты белән билгеле урын алган, шул ук вакытта үзбәк-татар әдәби бәйләнешләренә мөнәсәбәтле кайбер язучыларыбыз, ватандашларыбыз турында барыр. Татар әдәбияты һәм башка төрки халыклар иҗаты, бигрәк тә төрек, казах, төрекмән, үзбәк милли әдәбиятлары белән үзара бәйләнешләрен абруйлы галимебез Хатип Миңнегулов хезмәтләрендә табарга була[1]. Ул бу халыклар әдәбиятының берберсенә ничек йогынты ясау мәсьәләләрен җентекләп өйрәнгән шәхес.

20 йөз башы татар хатын-кызлары хәрәкәте активисты, шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева – исеме тарихта билгеле шәхес[2]. Революциягә кадәрге әдәби псевдонимы – Гыйффәт туташ. 1895 елда Рязань өлкәсендә туып үскән кыз яшьтән үк әдәбият белән кызыксына. 1914–1915 елларда газеталарда шигырьләрен бастыра. Кызганыч ки, Заһидәнең гаиләсе аның мәгърифәткә тартылуын хупламый, укырга керү теләгенә риза булмыйча, яңача карашлы бу кыю кызга төрле каршылыклар тудыра: аны өйләрендә ябып яткыралар, китапларын яндыралар һәм ахыр чиктә Заһидә әти-әнисе йортын ташлап чыгып китәргә мәҗбүр була, татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булып яңа тормыш өчен актив көрәш юлына баса: Мәскәүгә китеп урнаша, әдәби иҗат белән шөгыльләнә, “Вакыт” газетасы аша халыкка мөрәҗәгать итеп, белем алырга омтылган кешенең нинди каршылыкларга дучар булу ихтималы барлыгы турында яза, “Әнигә хат” (1916) исемле шигырендә өйдән китүенең сәбәпләрен ачып бирә Заһидә туташ. 1917 елда Урта Азия якларына китә, башта Сәмарканд шәһәрендә үзбәк телендә чыга торган “Михнәттәшләр тавыши” (“Голос тружеников”) газетасында мөхәррир булып эшли, шул чорда партия сафларына керә. 1918–1919 елларда Кәттә Курган шәһәрендә Өяз Мәгариф комиссары урынбасары вазифасын башкара, аннары Ташкент шәһәрендә оештырылган берьеллык мәгариф курсларын җитәкли. 1920–1921 елларда РКП(б) Үзәк Комитетының Төркестан бюросында хатын-кызлар белән эшләү бүлегенә җитәкчелек итә, бер үк вакытта Үзбәкстан хатын-кызлар мәгариф институты директоры була. 1920 елда ул Төркестан хатын-кызларының 1 нче съездында катнаша, М.Фрунзеның чыгышын үзбәк теленә тәрҗемә итә. Шул ук елны коммунист хатын-кызларның Мәскәүдә узган 1 нче Бөтендөнья конференциясендә дә катнаша. 1921–1923 елларда РКП(б) Үзәк Комитетының хатын-кызлар бүлеге инструкторы (Мәскәү). 1924 тән кабат Үзбәкстанда: Урта Азия коммунистик университетында бүлек мөдире, Урта Азия ефәк сәнәгате техникумы директоры,

Үзбәк дәүләт китап нәшриятының матур әдәбият секторы мөхәррире, Урта Азия революция тарихы фәнни-тикшеренү институты фәнни хезмәткәре вазифаларын башкара. 1933–1952 елларда Заһидә Бурнашеваның хезмәт биографиясе Кыргызстан белән бәйле: совет-партия мәктәбендә укыту бүлеге мөдире, Кыргызстан ССР Министрлар Советы каршындагы матбугат Баш идарәсе җитәкчесе, 1941–1945 елларда әдәбият һәм нәшрият эшләре буенча Баш идарә җитәкчесе, Бөтенсоюз юридик институтының Фрунзе филиалында уку-укыту бүлеге мөдире. Аның тырышлыгы, турыдан-туры җитәкчелеге астында 1920 елларда үзбәк, кыргыз, төрекмән, таҗик кызлары арасыннан күп кенә укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре үсеп чыга. Заһидә Бурнашева 1952 елда туган якларына әйләнеп кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр иҗат эше белән шөгыльләнә. Ул "Гыйффәт Туташ шигырьләре" (1915–1917) дип бер үк исем астында басылып чыккан өч җыентык авторы. Бу җыентыклардагы шигырьләр заманында укучылар арасында һәм әдәби тәнкыйть даирәсендә зур кызыксыну уята. 1971 елда аның "Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан" дип аталган китабы дөнья күрә. Автобиографик характердагы бу китап моңарчы билгесез архив материалларына һәм замандашларының истәлекләренә нигезләнеп язылган. Күпкырлы иҗтимагый эшчәнлеге, укыту-тәрбия һәм әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Заһидә Бурнашева "Почёт Билгесе" ордены, Үзбәкстан һәм Кыргызстан Югары Советлары Президиумының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Совет чоры үзенең сугышлары, авырлыклары, зур югалтулары, социаль-сәяси тетрәнүләре булуга карамастан, әдәбиятыбыз тарихында чагылыш тапкан зур бер этап. Тугандаш төрки халыклар арасында әдәби багланышлар һәм аларның бер-берсенә йогынтысы бу чорда да игътибарга лаек күренеш. Андый йогынты шул телдәге әдәбиятне оригиналда укып-танышу аркылы булса, икенче юлы – тәрҗемәләр ярәмендә тормышка ашырыла. Күбрәк аудитория таныша алсын өчен, күпмилләтле илнең халыклары әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү эше совет заманында яхшы куелган иде. Алай гына да түгел, әсәрләрен рус телендә иҗат итеп, китапларын миллионлаган тиражлар белән бастыра алган язучыларыбыз да байтак. Шундый талантлы милләттәшләребездән берсе – әтисе ягыннан Идел буе татары, әнисе ягыннан башкорт дворяннары (тарханнар) нәселеннән булган Башкортстанның Бәләбәй кантоны Исламбахты авылында туып үскән язучы, Урта Азия тарихына караган әсәрләр авторы Җәүдәт Хәсән улы Ильясов (1929–1982)[3]. 1934 елда ул әнисе белән Урта Азия якларына күченеп килә: балачагы, үсмер вакытлары шушы төбәктә, авыр хезмәттә, юклыкта уза. Башта үзбәк, аннары рус мәктәбендә укый. Башкортстанга Белорецк шәһәренә кайтып педа-

гогия училищесын тәмамлый. Кабат Үзбәкстанда слесарь, рәссам, клуб, китапханә, үзешчән сәнгать коллективлары җитәкчесе булып та эшли. Мәктәпләрдә үзбәк теле, рәсем, сызым дәресләрен укыта. 1949 елдан шигырьләре, хикәяләре басыла башлый. 1952 елдан Башкортстанның кайбер газеталарында корреспондент, "Ташкентская правда", "Комсомолец Узбекистана", "Физкультурник Узбекистана" газетасында әдәби хезмәткәр, соңрак "Звезда Востока" журналында бүлек мөдире вазифаларын башкара. Язучының иҗат кыйбласын тарихның борылыш мизгелләрендә халыклар язмышы белән кызыксыну билгеләгән. Аның әдәби геройлары – гаделлек, ирек өчен көрәшүчеләр, прототиплары булып аерым очракларда тарихи шәхесләр булган тормыш каһарманнары. Җәүдәт Ильясовның "Стрела и солнце" (1954), "Тропа гнева" (1956), "Согдиана" (1959), "Пятнистая смерть" (1964), "Черная вдова» (1966), "Золотой истукан" (1973), "Месть Анахиты" (1984), "Заклинатель змей" (1979), "Башня молчания" (1982) роман һәм повестьлары билгеле. "Тропа гнева" ("Нәфрәт сукмагы") тарихи повестендә сүз массагетларның Урта Азиягә басып кергән фарсыларга каршы көрәше турында. "Согдиана" романы Александр Македонскийның Урта Азиягә походын тасвирлый. "Пятнистая смерть" ("Тимгелле үлем") романы да тарихи темага язылган. Аның сюжжеты буенча "Томирис" балеты языла һәм ул Фрунзе шәһәрендә Кыргыз опера һәм балет академия театрында 1982 елда, Ташкентта А.Нәвои исемендәге Үзбәк Зур опера һәм балет театрында 1984 елда сәхнәгә куела. 1965 елда Җ.Ильясов һәм А.Ташкенбаева сценарийлары буенча "Канатоходец" ("Бауда йөрүче") нәфис фильмы төшерелә (режиссёры Р.Батыров). 1979 елда язучының урта гасырлар шагыйре һәм галиме Гомәр Хәйямгә багышланган трилогиясенең беренче китабы "Заклинатель змей" ("Еланнар әфсенләүче") басылып чыга. "Башня молчания" ("Тынлык манарасы") дип исемләнгән икенче китабы язылып бетми кала. Үзбәкстанда аның популяр романнарының гомуми тиражы берничә дистә миллион данә исәпләнә. Язучы күбрәк рус телендә иҗат итә, публицистикасы башлыча татар, үзбәк, башкорт телләрендә. Гарәп, инглиз, кырымтатар, каракалпак телләрен яхшы белә, үзбәк язучыларын, бигрәк тә Гафур Голямне рус теленә тәрҗемә итә. Җәүдәт Ильясовның гомере 1982 елның 19 июнендә фаҗигале үлем белән өзелә. Әдипнең тууына 60 яшь уңаеннан Ташкентта ул яшәгән йортта мемориаль такта куела.

Совет чорын тәнкыйтьләргә яратсак та, ул чорның аерым кыйммәтләре булуына тарих шаһит. Советлар Союзы халыклары тормышның төрле өлкәләрендә, шул исәптән мәдәният, сәнгать өлкәсендә дә аралашып яши. Милли республикаларда төрле милләт халыкларының сәнгатенә, мәдәниятенә багышланган

фестивальләр, декадалар, иҗади очрашулар еш үткәрелеп килә, СССР таркалу белән милләтләр арасындагы мондый тыгыз элемтә юкка чыга диярлек. 1990 елларда милли үзаң үсеше, тарихка яңача караш, милләтнең язмышы белән кызыксыну кабат арта. Чит мәмләкәтләрдә гомер кичергән милләттәшләребезнең ничек яшәүләре турында матбугатта язмалар күренә башлый. Мондый мәгълүматларны халыкка җиткерүнең чишмә башында татарлардан Тәүфик Әйди (1941–2001) торды дип әйтергә була. Ул үзе Мәскәү өлкәсендә туса да, балачагы Апас якларында уза. Аннары гаиләләре белән Омск якларына күченеп китәләр, булачак язучы шунда казакъ мәктәбендә белем ала. Киләчәктә кардәш халыкларның мәдәнияте белән кызыксыну да шунда башлангандыр бәлкем. Әдип төрки телле әдәбиятлар вәкилләреннән С.Морәтбәков, А.Сатаев, Ә.Мохтар, Ү.Һашимов әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Ерак сәфәрләргә чыгып йөргән кеше буларак Т.Әйди төрки дөньяны күп күргән, яхшы белә. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең эшчәнлеген, тормышын өйрәнеп ул “Кайда да кадерле” (1984), “Безгә ни булды?” (1991), “Йөртә безне язмышлар” (1992), “Аһ, туган каумем газиз” (1993), “Оҗмах утравы” (1999), “Кардәшләр кочагында” (2000) җыентыкларын бастырып чыгара. Аның бу эссе, юлъязмалары татар халкының күренекле вәкилләренә, татарларның милли яңарыш проблемаларына һәм үзаңы үсешенә багышланган.

Ә матур әдәбияткә килсәк, бүгенге көндә татар әдәбиятында Урта Азиядәге тарихи вакыйгаларны тасвирлаган әсәрләр күп түгел. Андыйларга Әсгать Айдарның “Ташбай” (1932), Шамил Усмановның “Памирдан радио” (1925) повестьларын күрсәтергә мөмкин. Шул теманы дәвам иткән Тәүфик Әйдинең “Елан угы” (1991) романы аерым игътибарга лаек. Романда Бохара ханлыгы җимерелгәннән соң башланган чуалышлар сурәтләнә. Сәяси детектив характерында язылган бу әсәрдә татарларның да революцияне экспортлауда катнашуы, сыйнфый көрәшне куертуның җирле халыкларга да, яңа битлек кигән колонизаторларга хезмәт итүче татарларга да бәхет китермәве, киресенчә, яңа фаҗигаләргә генә юл ачуы гәүдәләндерелә. Татарларның Төркестанда ике тарафка аерылып, большевиклар һәм “басмачылар” сафында үзара көрәше, кан коюы тарихи ялгышлык нәтиҗәсе буларак сурәтләнә.

Тәүфик Әйди әсәрләре жанры ягыннан да, эчтәлеге белән дә әдәбиятыбызга яңалык алып килде, бу хезмәтләренә салынган уйхисләре белән татар укучысының милли аңын уяту-үстерүгә зур өлеш кертте.

Без бу мәкаләдә өч шәхеснең иҗат биографиясенә кыскача күзәтү ясадык. Гыйффәт Туташ тормышы, яшәеше, шәхес буларак формалашуына чит мохит, тугандаш халыклар берлеге ярдәм

итсә, язучы Җәүдәт Ильясов өчен Үзбәкстан илһам чыганагы була: әдип тарихи романнары, әдәби тәрҗемәләре белән республикада таныла. Тәүфик Әйди исә, күп җирләргә сәяхәт итүләренә нигезләнеп, шул исәптән Урта Азия халыкларының тормышын яхшы белеп, халыклар арасындагы каршылыклы, бәхәсле моментларны да сурәтләргә алына. Иҗатлары бер-берләрен һич тә кабатламый торган бу өч әдип татар-үзбәк әдәби багланышлары даирәсен һәркайсы үзара баета, аларның бу өлкәдә куйган хезмәтләре, яулаган биеклекләре безнең дә аң-күңел офыкларыбызны киңәйтүгә зур өлеш кертә.

**Сведения об авторе:** Габдулхакова Гульшат Мансуровна, научный сотрудник Центра регионоведения и социокультурных исследований Института татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ, e-mail: sofa-hakova69@mail.ru.

БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЙ СПИСОК

1 Миннегулов Х. Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей. – Казань: “Ихлас”, 2017. С.126–130, 261–265.

2 Өмет йолдызлары. – Казан, 1988. С.208.

3 Писатели Советского Узбекистана. – Ташкент, 1977. С.75.

**Аннотация:** Многие деятели татарской литературы внесли значительный вклад в развитие национальных культур народов СССР. Татары и узбеки, как и другие тюркские народы, имели многовековые литературные взаимосвязи, сотрудничали. В статье рассматривается творчество некоторых писателей, чьи судьбы связаны с Республикой Узбекистан.

**Ключевые слова:** татарская литература, литературные взаимосвязи, татарская диаспора.

**Abstract:** Many figures of Tatar literature made a significant contribution to the development of national cultures of the peoples of the USSR. Tatars and Uzbeks, like other Turkic peoples, had centuries-old literary relationships and collaborations. The article discusses the works of some writers whose fates are associated with the Republic of Uzbekistan.

**Key-words:** Tatar literature, literary relationships, Tatar diaspora.